**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәреш кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2015 елның 30 июлендәге ПУ-688 номерлы, 2017 елның 20 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2017 елның 14 октябрендәге ПУ-911 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-58 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге ПУ-339 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге ПУ-154 номерлы, 2021 елның 2 мартындагы ПУ-194 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 июлендәге 506 номерлы, 2024 елның 26 июлендәге 565 номерлы, 2025 елның 17 июлендәге 547 номерлы һәм 2026 елның 20 февралендәге 153 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына, Комиссия әгъзасы М.С. Дәлкарнәевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә: «Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 08 август
№ 642